РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
ГЛАВА
СТАРОСТУДЕНЕЦКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ СУЫКСУ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

Иске Суыксу авылы

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13 март 2026 ел № 3

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Суыксу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Боерган тимер юл разъезды поселогы торак пунктын бетерү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү хакында.

Буа муниципаль районының Иске Суыксу авыл җирлеге халкының Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Суыксу авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Суыксу авыл җирлеге составына керүче Боерган тимер юл разъезды поселогы торак пунктын бетерү турында» карары проектын тикшерүдә катнашу хокукларын үтәү максатларында, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Иске Суыксу авыл җирлеге Уставына таянып, карар бирәм:

1. 2026 елның 13 мартында җирлекнең мәгълүмат стендларында игълан ителгән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Иске Суыксу авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Иске Суыксу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Боерган тимер юл разъезды поселогы торак пунктын бетерү турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрергә.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.:

ТР, Буа районы, Иске Суыксу ав., Совет ур., 28 й.;

ТР, Буа районы, Яңа Суыксу ав., Мәктәп ур., 4 й.

Билгеләргә:

2.1 гавами тыңлауларны үткәрү вакыты-2026 елның 10 апрелендә 10.00 сәгатьтә;

2.2 уздыру вакыты - 1 көн;

2.3 уздыру урыны - ТР, Буа районы, Иске Суыксу авылы, Совет ур, 26й;

2.4 фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырыла торган, чыгыш ясау хокукы булган гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирелә торган адрес: ТР, Буа районы, Иске Суыксу авылы, Совет урамы, 28 йорт (эш көннәрендә-8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр)

2.5 чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга гаризалар бирү вакыты-2026 елның 02 апреленә кадәр.

3. Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлеге башкарма комитетына билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Иске Суыксу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керүче Боерган тимер юл разъезды поселогы торак пунктын бетерү турында» карар проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Иске Суыксу авыл җирлеге башлыгы М.М. Дәүләтшин